Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Лубян авыл җирлеге Советы

КАРАР

13 ноябрь 2020 ел № 24

«Җир салымы турында» Лубян авыл җирлеге Советының 2013 елның 21 ноябрендәге 20 номерлы карарының 4 пункты үз көчен югалткан дип тану хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Лубян авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» Лубян авыл җирлеге Советының 2013 елның 21 ноябрендәге 20 номерлы карарының 4 пункты (Лубян авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 30 номерлы, 2015 елның 30 маендагы 18 номерлы, 2015 елның 18 ноябрендәге 23 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 5 номерлы, 2018 елның 16 ноябрендәге 26 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 31номерлы, 2018 елның 20 декабрендәге 34 номерлы, 2019 елның 28 ноябрендәге 21 номерлы, 2020 елның 28 гыйнварындагы 1 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук Лубян авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер айдан соң үз көченә керә.

Янил авыл җирлеге башлыгы: Г.Ф.Тежикова